МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.12.2020 г. Казань № нов-1326/20

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезендә боерык бирәм:

1. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының
11.12.2020 №под-1326/20
боерыгы белән расланды

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Регламент Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

а) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка алырга теләүче Россия Федерациясенең балигълык яшенә җиткән гражданнары;

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) опека һәм попечительлек органы (алга таба – опека һәм попечительлек органы) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек органы шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш көн саен эшли. Эш сәгатьләре опека һәм попечительлек органының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы – һәр көнне, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, опека һәм попечительлек органының эш сәгатьләрендә.

1.3.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, опека һәм попечительлек органының мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында (https://mon.tatarstan.ru/rus/), Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) опека һәм попечительлек органына телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) опека һәм попечительлек органына язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – күпфункцияле үзәк) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органнарының урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта, рәсми сайт адресы, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, башкарма комитетның https://mon.tatarstan.ru/rus/zashita_prav_organi_opeki.htm рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.

Министрлыкның, опека һәм попечительлек органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында, мөрәҗәгать итүче белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) башкарма комитетның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәте – федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының, җирле үзидарә органының функцияләрен тормышка ашыру эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чигендә мөрәҗәгать итүчеләрнең рәсми мөрәҗәгатьләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торган), 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына, норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

опека – опека һәм попечительлек органы билгеләгән гражданнар (опекуннар) үзләре тәрбиягә алган балаларның законлы вәкилләре булып тора торган һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик әһәмияткә ия барлык эшләрне башкара торган итеп кече яшьтәге (ундүрт яшенә җитмәгән балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны) гражданнарны урнаштыру формасы;

попечительлек – опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданин (опекун) әлеге затларга үз хокукларын гамәлгә ашыруда һәм бурычларын үтәүдә, шулай ук өченче затлар ягыннан алардан явыз нияттә файдаланудан саклауды булышлык күрсәтергә бурычлы булырлык итеп ундүрт яшьтән олырак балигълык булмаган гражданнарны урнаштыру формасы;

түләүсез шартларда опека (попечительлек) мөрәҗәгать итүче белән туганлык мөнәсәбәтләрендә торган балигъ булмаган затлар өчен билгеләнә, бу баланы сайлау процедурасын төшереп калдыра;

түләүле шартларда опека (попечительлек) мөрәҗәгать итүче белән туганлык мөнәсәбәтләрендә тормаган балигъ булмаган затлар өчен билгеләнә, бу баланы сайлап алу һәм опекага алынган балага карата опека яки попечительлек гамәлгә ашыру турында килешү, шул исәптән тәрбиягә бала алган гаилә турында килешү

(алга таба – баланы тәрбиягә алучы гаилә), яисә тиешле Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда, – патронат гаилә турында килешү төзүне күздә тота.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла. Гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандарт таләпләре эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую | Россия Федерациясе Гаилә кодексының 19 бүлеге (алга таба – РФ Гаилә кодексы); Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 бүлеге (алга таба – ТР Гаилә кодексы); РФ Хөкүмәтенең «Балаларны уллыкка (кызлыкка) бирү һәм Россия Федерациясе территориясендә уллыкка (кызлыкка) алучылар гаиләләрендә аларның яшәү һәм тәрбия шартларын тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| | | карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары) белән расланган Балаларны уллыкка (кызлыкка) бирү һәм Россия Федерациясе территориясендә уллыкка (кызлыкка) алучылар гаиләләрендә аларның яшәү һәм тәрбия шартларын тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләре;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче затларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2012 елның 8 февралендәге 90 номерлы карары (алга таба – 90 номерлы ТР МК карары) |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) опека һәм попечительлек органы | РФ Гаилә кодексының 19 бүлеге; |

| | | |
|---|---|---|
| | | ТР Гаилә кодексының 19 бүлеге;<br>«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы);<br>«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьясы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы |

| | | |
|---|---|---|
| | | Законы);<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларны уллыкка (кызлыкка) бирү һәм Россия Федерациясе территориясендә уллыкка (кызлыкка) алучыларның гаиләләрендә аларның яшәү һәм тәрбия шартларын тикшереп тору кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе гражданнары һәм чит ил гражданнары яки гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан уллыкка (кызлыкка) алынган балаларны Россия Федерациясе консуллык учреждениеләрендә исәпкә кую кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы карарының (алга таба – 275 номерлы Кагыйдәләр) 3 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте | Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында | РФ Гаилә кодексының 19 |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | бәяләмә һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую/яки уллыкка (кызлыкка) алучы була алмау мөмкинлеге турында бәяләмә | бүлеге;<br>ТР Гаилә кодексының 19 бүлеге;<br>275 номерлы Кагыйдәләрнең 9 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Дәүләт хезмәте гаризаны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү (җибәрү) бәяләмә имзаланганнан соң 3 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. | 275 номерлы Кагыйдәләр;<br>90 нчы номерлы ТР МК карары |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен | Баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү үтенече белән гариза (алга таба – гариза) (әлеге Регламентның 1 нче кушымтасы) тапшыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: | РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче гражданнарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);<br>уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче гражданнарның шәхесен таныклаучы документлар турында белешмәләр;<br>уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче гражданнарның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр;<br>гражданинда РФ Гаилә кодексының 127 статьясындагы 1 пунктының 9-11 пунктларында күрсәтелгән хәлләр булмавын раслаучы белешмәләр;<br>алына торган пенсия, аның төре һәм күләме турында белешмәләр (төп керем чыганагы мәҗбүри пенсия иминияте буенча иминият тәэминаты яки башка пенсия түләүләре булган затлар өчен).<br>Баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче гражданнар гариза тапшыру датасын күрсәтеп, анда күрсәтелгән белешмәләрне, шулай ук төгәл булмаган яки ялган мәгълүмат тапшырган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык турында хәбәрдар булуларын имзалары белән раслыйлар.<br>Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче затның кыскача автобиографиясе;<br>уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләгән затның, вазыйфасын һәм соңгы 12 ай өчен уртача хезмәт хакын күрсәтеп, эш урыныннан белешмә һәм (яки) әлеге затның керемнәрен раслый торган башка документ, яки уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләгән затның иренең (хатынының) эш урыныннан аның вазыйфасын һәм соңгы 12 ай өчен уртача | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәт хакы күләмен күрсәтеп белешмә һәм (яки) әлеге зат иренең (хатынының) керемнәрен раслый торган башка документ;<br>ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка), тәрбиягә алучы гаиләгә яки патронат гаиләгә опекага (попечительлеккә) алырга ниятләгән гражданнарны медицина ягыннан таныклау турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2014 елның 18 июнендәге 290н номерлы боерыгы белән расланган медицина документациясенең 144/у номерлы исәпкә алу формасы буенча) билгеләгән тәртиптә рәсмиләштерелгән бәяләмә;<br>- чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән гаилә кору турында таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль билгеләнгән, рус теленә тәрҗемәсе (әгәр дә баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче гражданнар өйләнешкән булса һәм гаилә кору чит дәүләт территориясендә теркәлгән булса);<br>- ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләк белдергән затларның РФ территориясендә әзерлек узуы турында таныклык күчермәсе (баланың якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алучы булып торган һәм үзләренә карата уллыкка (кызлыкка) алу гамәлдән чыгарылмаган затлардан тыш, һәм балаларның опекуннары (попечительләре) булган яки булып торган һәм үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш). Әлеге таныклык формасы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан раслана. | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 7 статьясының 6 өлешендәге 3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Россия Федерациясенең аз санлы төп халыкларына караган, күчмә һәм (яки) ярым күчмә яшәү рәвеше алып барган һәм даими яки нигезле рәвештә яши торган урыннары булмаган гражданнар, Россия Федерациясенең азсанлы төп халыкларына караган затлар арасыннан уллыкка (кызлыкка) бала алган очракта, гаризада Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган, Россия Федерациясенең аз санлы төп халыкларының традицион яшәү урыннары һәм традицион хуҗалык эшчәнлеге исемлеген исәпкә алып, әлеге җирлекнең җирле администрациясенең адресы буенча әлеге гражданнарның күчмә маршрутлары уза торган чикләрдәге муниципаль районда булган җирлекләрнең (әлеге гражданнар ихтыярына карап) берсендәге яшәү урыны буенча теркәлү турындагы мәгълүматларны күрсәтәләр.<br>Россия Федерациясенең аз санлы төп халыкларына караган, күчмә һәм (яки) ярым күчмә яшәү рәвеше алып барган һәм даими яки нигезле рәвештә яши торган урыннары булмаган гражданнар гаризага әлеге пунктның 9-13 абзацларында күрсәтелгән документларны, шулай ук әлеге гражданнарның күчмә һәм (яки) ярым күчмә яшәү рәвеше алып барылуын раслый торган, тиешле муниципаль районның җирле үзидарә органы тарафыннан бирелгән документларны да теркиләр. | |
| | Әлеге пунктның 10 абзацында күрсәтелгән документ бирелгән көннән башлап бер ел дәвамында гамәлдә була, әлеге пунктның 11 абзацында күрсәтелгән документ бирелгән көннән башлап 6 ай эчендә гамәлдә була. | 275 номерлы Кагыйдәләрнең 9(1) пункты |
| | Уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую өчен, 432 номерлы Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә опекун була алу мөмкинлеге турында бәяләмәсе булган затлар гариза һәм опекун була алу мөмкинлеге турында бәяләмә тапшыра. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче опека органына шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, аларны электрон имза белән имзалау мәҗбүри шарт булып тора. | «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан соратып алына торган документлар:<br>1. Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);<br>2. Эчке эшләр органнарыннан гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә аңлы рәвештә җинаять кылган өчен хөкем ителмәү турында белешмә (РФ Эчке эшләр министрлыгының ТР | РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | шәһәрләре һәм районнарындагы территориаль органнары);<br>3. Алына торган пенсия, аның төре һәм күләме турында белешмәләр (төп керем чыганагы мәҗбүри пенсия иминияте буенча иминият тәэминаты яки башка пенсия түләүләре булган затлар өчен);<br>4. Гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (әгәр баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләгән гражданнар өйләнешкән булса һәм гаилә кору Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән булса (вәкаләтле органнардан)).<br>Әлеге документлар, биреләчәк мәгълүматның конфиденциальлеген саклау максатларында мөрәҗәгать итүчедән алдан ук ризалык алып, опека һәм попечительлек органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.<br>Әлеге мәгълүматларны тапшырганда уллыкка (кызлыкка) алу сере сакланырга тиеш. Аны тараткан өчен гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүмат тапшыруны яки гамәлләр башкаруны мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен | |

| | | |
|---|---|---|
| | раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документлар тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Тапшырыла торган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган төзәтүләр булуы.<br>2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы күләмендә тапшырылмавы.<br>3. Балигъ булмаган баланың яшәгән урынына карамаган урын буенча мөрәҗәгать итү. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1. Опека һәм попечительлек органына дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, гариза белән мөрәҗәгать итүче гражданинга (гражданнарга) хезмәт күрсәтүдән баш тартыла, әгәр мөрәҗәгать итүче(ләр) түбәндәге категорияләргә караса:<br>1) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез дип танылган;<br>2) берсе суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез дип танылган ир белән хатын;<br>3) суд нигезендә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокукларында чикләнгән затлар;<br>4) закон белән йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;<br>5) әгәр уллыкка (кызлыкка) алу алар гаебе белән суд | 275 номерлы Кагыйдәләр; РФ Гаилә кодексының 127 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезендә гамәлдән чыгарылган булса, элеккеге уллыкка (кызлыкка) алган затлар;<br>6) сәламәтлеге буенча ата-ана хокукларын гамәлгә ашыра алмый торган затлар;<br>7) уллыкка (кызлыкка) алу билгеләнгән вакытка уллыкка (кызлыкка) алучылар яши торган Россия Федерациясе субъектында уллыкка (кызлыкка) алыначак баланы тәэмин итәрлек кереме булмаган затлар;<br>8) даими яшәү урыны булмаган затлар;<br>9) уллыкка (кызлыкка) алу мизгеленә аңлы рәвештә кеше гомеренә яки сәламәтлегенә каршы җинаять кылган өчен хөкем ителгән затлар;<br>10) санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга җавап бирми торган торак урыннарында яши торган затлар.<br><br>2. Үзара өйләнешеп яшәми торган затлар бер үк баланы бергә уллыкка (кызлыкка) ала алмыйлар.<br>3. Мөрәҗәгать итүченең уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында карар кабул итү вакытына опека һәм попечительлек органында әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшырылган документларның оригиналлары булмавы.<br>4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү хокукын билгеләү өчен нигез булган документларны тиешенчә рәсмиләштерелмичә, тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр тапшырылуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү | Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен | РФ Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» |

| | | |
|---|---|---|
| турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | чират билгеләнмәгән. | 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы Указының) 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза тапшырылган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчене кабул итү махсус бүлеп бирелгән, түбәндәгеләр белән тәэмин ителгән урыннарда гамәлгә ашырыла:<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар белән;<br>мәгълүмат стендлары белән.<br>Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, объектлардан файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы | РФ Президентының 601 номерлы Указының 1 пункты;<br>«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон;<br>Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының |

| | | |
|---|---|---|
| мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | шартлар тудырыла:<br>а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;<br>б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;<br>г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы житешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу мөмкинлеге;<br>д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;<br>е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәттән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;<br>ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2015 | «Мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтелә торган объектлардан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар өчен файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук бу вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 9 ноябрендәге 1309 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | елның 21 июлендә теркәлгән, теркәлү номеры – 38115) белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, хезмәт күрсәтелә торган объектка сукырларны озата йөри торган этне кертү.<br>2016 елның 1 июленнән соң шулай ук капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы, инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең | |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплексы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки аннан файдалана алмау | булмавы белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү буенча документлар кабул иткәндә чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозулар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтә торган муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәткән муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүе күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы Регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнеңерактагы эш урыннарында күрсәтелгәндә, консультацияләүне, документларны кабул итү һәм бирүне күпфункцияле үзәк белгече гамәлгә ашыра.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – җирле үзидарә органы һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан башкарма комитет сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, | |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәк аша алынырга мөмкин<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Консультация шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша (mon@tatar.ru) электрон хәбәр рәвешендә бирелергә мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты рәсми сайтыннан, шулай ук Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен аларның 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы мәҗбүри шарт булып тора.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм документлар күпфункцияле үзәк, читтән торып эшләү урыны аша тапшырылган очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, читтән торып эшләү урыны хезмәткәре консультацияли, документларны кабул итә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат бирә. | 63-ФЗ номерлы Федераль закон |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидат була алу мөмкинлеге турында бәяләмә / уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидат була алу мөмкинлеге булмавы турында карар әзерләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) торак-көнкүреш шартларын тикшерү (3 нче кушымта);

5) уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкинлеге булмау турында карар кабул итү;

6) уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидат буларак исәпкә кую;

7) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яки) хат нигезендә опека һәм попечительлек органына дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, консультация бирә.

Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчене дәүләт хезмәтен алу предметы буенча консультацияли, дәүләт хезмәте күрсәтү турында бланк тапшыра һәм, зарурлык булганда, гариза бланкысын тутыруда ярдәм күрсәтелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, кисәтүләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә яисә электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яки почта буенча, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы юллама белән әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, опека һәм попечительлек органына гариза тапшыра (җибәрә).

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта сорала торган документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре кушыла, гариза почтадан җибәрелгән, – мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар.

3.3.2. Гариза биргәндә белгеч:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

гариза белән документларны кабул итә;

документлар булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә (документларның күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннарның һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннарының булу-булмавын) туры килү-килмәвен тикшерә;

гариза формасы нигезендә гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүматның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) булуына карата гаризаны тутыру тулылыгын тикшерә;

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече гаризаны терки, рөхсәт бирү турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кабул итү датасы турында тамгалап, гаризаны тапшыру ысулуына карап, исемлек күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә яки электрон формада юллый һәм мөрәҗәгать итүченең гаризасын һәм документларны, карар кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон формада опека һәм попечительлек органына җибәрә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм опека һәм попечительлек органына җибәрелгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Опека һәм попечительлек органы белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

эчке эшләр органнарыннан гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә аңлы рәвештә җинаять кылган өчен хөкем ителмәү турында белешмә (РФ Эчке эшләр министрлыгының ТР шәһәрләре һәм районнарындагы территориаль органнары);

алына торган пенсия, аның төре һәм күләме турында белешмәләр (төп керем чыганагы мәҗбүри пенсия иминияте буенча иминият тәэминаты яки башка пенсия түләүләре булган затлар өчен);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (әгәр баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләгән гражданнар өйләнешкән булса һәм гаилә кору Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән булса (вәкаләтле органнардан)).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опека һәм попечительлек органына җибәрелгән белешмәләр яисә баш тарту турында белдерү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Опека һәм попечительлек органы белгече тапшырылган документларны һәм рәсми мөрәҗәгатьләргә җавапларны карый.

Мөрәҗәгать итүченең яшәү шартларын, торак-көнкүреш шартларын, мөрәҗәгать итүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аны бала тәрбияләүгә сәләтен, мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне бәяләп тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре нигезендә тикшерү акты әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты.

3.5.2. Кергән белешмәләр һәм тикшерү акты нигезендә опека һәм попечительлек органы белгече:

уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге /мөмкинлеге булмау турында карар кабул итә;

уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә проекты яки уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлегенең булмавы турында бәяләмә проекты әзерли;

бәяләмә бирү турында боерык проектын имзалау өчен җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) имзалау өчен юнәлдерелгән проектлар.

3.5.3. Җитәкче (ул вәкаләт биргән зат) бәяләмәне раслый, боерыкка кул куя һәм аны мөһер белән таныклый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура проектлар раслау өчен килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкинлеге булмау турында расланган бәяләмә.

3.5.3. Опека һәм попечительлек органы белгече:

Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкинлеге булмау турындагы бәяләмәне терки.

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән

бәяләмә бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар җитәкче тарафыннан документларга кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

3.5.4. Уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидат буларак исәпкә кую.

Опека һәм попечительлек органы мөрәҗәгать итүченең уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турындагы бәяләмә нигезендә аның турындагы мәгълүматны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче затларны исәпкә алу журналына кертә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура бәяләмә имзаланганнан соң 3 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: журналга мәгълүмат кертү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә бирә яки почта аша җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче нәтиҗәне электрон рәвештә алу ысулын сайлаган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында җибәрә.

Шәхсән килгәндә, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) расланган карарны бирелгән карарлар журналында карарны алу турында имзалатып бирә яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, карар бирүдән баш тарту турында хат тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

15 минут эчендә – мөрәҗәгать итүче шәхсән килгән очракта;

җавап почта аша җавап җибәрелгән очракта, алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә.

3.7. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкин булмавы турындагы бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатны) үзгәртеп рәсмиләштерү бәяләмәдә (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатта) җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкин булмавы турындагы бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатны) үзгәртеп рәсмиләштерү, техник хаталары (язу, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган документны теркәп, теркәлгән гариза (киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентка 5 нче кушымтада китерелгән) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.1. Опека һәм попечительлек органы белгече:

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкинлеге булмау турындагы бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү.

Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкинлеге булмау турындагы бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатны) имзалау өчен җитәкчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, техник хатаны төзәтү турында теркәлгән гариза. Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге/мөмкинлеге булмау турында имзалау өчен җитәкченә җибәрелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатны) үзгәртеп рәсмиләштерү.

3.7.2. Җитәкче бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатны) имзалый һәм аны опека һәм попечительлек органы белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләмә проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат).

3.7.3. Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат) турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат) турында хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, карарлар кабул итүдән һәм опека һәм попечительлек органының вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүдән тора.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларның проектларына хокукый экспертиза уздыру. Экспертизалар нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

эшчәнлек алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;

дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки

мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатенә бәйле мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшырылырга мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның сроклары, эзлеклелеге һәм эчтәлеге бозылу очраклары һәм сәбәпләре турында белгечләр кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган җитәкчесенә хәбәр итә, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрә.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Бүлек җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралуын контрольдә тота.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгән кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр өчен җаваплы башкаручылар законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә опека һәм попечительлек органы эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Башкарма комитет хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – Башкарма комитет җитәкчесенә, Башкарма комитет җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) муниципаль берәмлек башлыгына судка кадәр тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле

үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.4. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, муниципаль берәмлекнең

рәсми сайты, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яки мондый төзәтмәләрне кертү чоры бозылганда, – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый

актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, Башкарма комитетта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында, алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны эз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) гариза белән документларны опека һәм попечительлек органына җибәрү;

4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яки электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынына документлар тапшыра.

Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү турында гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

6.3.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

5.4. Опека һәм попечительлек органына гариза җибәрү:

6.4.1. Күпфункцияле үзәк белгече гаризаны һәм документларны опека һәм попечительлек органына күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап алынгач, документлар пакетын формалаштыра һәм аны күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә башкарма комитетка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәк белән үзара хезмәттәшлек турындагы килешүдә билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опека һәм попечительлек органына җибәрелгән документлар.

6.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

6.5.1. Күпфункцияле үзәк белгече, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен опека һәм попечительлек органыннан алган вакытта, аны билгеләнгән тәртиптә терки, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар башкарма комитеттан документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

6.5.2. Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыра

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) опека һәм попечительлек органына
кемнән ___________________________
(фамилия, исем, ата исеме)

Уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирүегезне үтенәм

Мин ______________________________________-_______________________________,
фамилия, исем, ата исеме
Туган көн: _____________________ Гражданлык: ______________________________
Паспорт: серия __________ № _______________ бирелгән датасы ______________
____________________________________________________________________________
кем тарафыннан бирелгән ___________________________________________________
____________________________________________________________________________
Адрес (теркәлү урыны буенча): ______________________________________________
Адрес (фактик): ________________________________________________________

Тапшырылган документлар:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
____________________________________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме тулысынча)
Гаризаны тутыру датасы____________________________________________________

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Балигъ булмаган гражданинның опекуны яисә попечителе булырга яисә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты

Тикшерү датасы «___»_________________ 20____ ел.
Тикшерү үткәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы ____________________________________________________________
Түбәндәгенең тормыш шартларын тикшерү үткәрелде
________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме
________________________________________________________________________;
(булган очракта), туган көне)
шәхесне раслаучы документы: ___________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
яшәү урыны _____________________________________________________________
(теркәлү белән расланган яшәгән урын адресы)
________________________________________________________________________
тору урыны _____________________________________________________________
(фактта яшәү һәм тикшерү үткәрелгән урын адресы
________________________________________________________________________
Белеме _________________________________________________________________
Һөнәри эшчәнлеге _______________________________________________________
________________________________________________________________________
(адресын, биләгән вазыйфасын, эш телефонын күрсәтеп, эш урыны)
Яши торган торагының мәйданы _________________________________________,
Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
_____ кв. м тәшкил итә, _______________ бүлмәдән тора, һәр бүлмәнең зурлыгы: ________ кв. м, ______________ кв. м, __________ кв. м. _____ катта _______ катлы йортта.
Йортның сыйфаты (кирпеч, панель, агач һ. б.; нормаль хәлдә, тузган, авария хәлендә; бүлмәләре коры, якты, тәрәзәләр саны һ.б.) ______________________________
________________________________________________________________________

Йортны һәм торак мәйданын төзекләндерү (суүткәргеч, канализация, нинди җылылык, газ, ванна, лифт, телефон һ.б.):

Торак мәйданының санитар-гигиена торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнмәслек)

Балага йөклау, уеннар, дәресләр, шәхси әйберләр өчен аерым бүлмә, почмак булуы

Торак мәйданында билгеләнгән тәртиптә яшиләр (билгеләнгән тәртиптә теркәлгәннәр һәм фактта яшиләр):

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | туган көне, ае, елы | Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәте | Әлеге торак мәйданында кайсы вакыттан бирле яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләр

(гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрнең холкы, балалар белән, балалар арасында үзара аралашу үзенчәлекләре һ.б.)

Гражданинның шәхси сыйфатлары (характерының үзенчәлекләре, гомуми культурасы, балалар белән аралашу тәҗрибәсе булуы һ.б.)

Балигълык яшенә җитмәгән баланы гаиләгә кабул итү өчен гражданинның мотивлары

Тикшерүнең өстәмә мәгълүматлары

Балигъ булмаган гражданинның опекуны яисә попечителе булырга яисә ата-ана

тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартлары _______________________________________-
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
(канәгатьләндерерлек/канәгатьләндерерлек түгел, конкрет шартларын күрсәтеп)

_______________________________________________________________

Тикшерү үткәргән затның имзасы ______________________________________

________________________ ____________ ______________________
(опека (попечительлек) органы җитәкчесе) (имзасы) (Ф.И.А.)

мөһер урыны

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

форма

БӘЯЛӘМӘ

гражданинның (гражданнарның) яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органыннан бирелгән, гражданинның уллыкка (кызлыкка) алучы яки опекун (попечитель) була алу мөмкинлеге турында

Ирнең яисә хатынның фамилиясе, исеме, ата исеме (тулысынча, ата исеме – булган очракта) ____
______________________________________________________________________________

Туган көне:_________, теркәлү адресы: ____________________________________________
______________________________________________________________________________

(почта индексын күрсәтеп)

Ир белән хатынның икенчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча, ата исеме – булган очракта) яисә ир белән хатын икесе бергә мөрәҗәгать иткән очракта)
______________________________________________________________________________

Туган көне:_________, теркәлү адресы: ____________________________________________
______________________________________________________________________________

(почта индексын күрсәтеп)

Яши торган адрес:_______________________________________________________________

(почта индексын күрсәтеп)
______________________________________________________________________________

Гаиләгә сыйфатлама (составы, гаилә булып яшәү озынлыгы (икенче тапкыр гаилә кору очрагында, алдагы гаиләдәге балаларны күрсәтергә), балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, якын туганнары булуы һәм аларның баланы гаиләгә тәрбиягә алуга карата мөнәсәбәте, уллыкка (кызлыкка), опекунлыкка (попечительлеккә) алу, тәрбиягә алучы ата-ана, патронат тәрбиячеләр буенча кандидатның холык үзенчәлекләре); ир белән хатынның берәрсе тарафыннан баланы уллыкка (кызлыкка) алган очракта икенчесенең уллыкка (кызлыкка) алуга ризалыгын күрсәтергә, опека (попечительлек) билгеләнгән очракта – опекун (попечитель) булырга теләгән гражданин белән бергә яши торган, 10 яшенә җиткән балаларның фикерен исәпкә алып, барлык балигълык яшенә җиткән гаилә әгъзаларының баланы (балаларны) гаиләгә кабул итүгә ризалыгы).
______________________________________________________________________________

Белеме һәм һөнәри эшчәнлеге___________________________________________________
______________________________________________________________________________

Сәламәтлек торышына сыйфатлама (гомуми сәламәтлек торышы, баланы гаиләгә тәрбиягә алуга комачаулый торган авыруларының булмавы)
______________________________________________________________________________

Матди хәле (мөлкәте, хезмәт хакының күләме, башка керем төрләре, керем күләменең төбәктә билгеләнгән яшәү минимумына нисбәте)____________________________________

Гражданинда Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясындагы 1 пунктының 9 һәм 10 пунктчаларында һәм 146 статьясының 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән шартларның булмавын раслый торган белешмәләр

________________________________________________________________________

Бала (бала) гаиләгә тәрбиягә алу өчен мотивлар_____________________________________

________________________________________________________________________

Бала (балалар) кандидатурасы буенча теләкләр (балалар саны, җенесе, яше, аларның сәламәтлек торышы) ___________________________________________________________

________________________________________________________________________

Мөмкин булуы/мөмкин булмавы турында бәяләмә __________________________________

________________________________________________________________________

(уллыкка (кызлыкка) алучы яки опекун (попечитель) булуга кандидат булган мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)):

________________________________________________________________________

(гражданинның (гражданнарның) кандидат була алу мөмкинлеге/мөмкин булмавы турында карар)

________________________________________________________________________

уллыкка (кызлыкка) яки опекунлыкка (попечительлеккә) алу

________________________________________________________________________

гражданинның балаларның саны һәм сәламәтлеге торышына кагылышлы теләкләрен исәпкә алып кабул ителә,

________________________________________________________________________

уллыкка (кызлыкка) алучы яки опекун (попечитель) булуга кандидат була алу мөмкинлегенең булмавы турында карар кабул ителгән очракта, гражданинның (гражданнарның) уллыкка (кызлыкка) алучы яки опекун (попечитель) буенча кандидат була алу мөмкинлегенең булмавы турында карар кабул итүгә нигез булган норматив хокукый актларның нормаларын күрсәтеп, баш тарту сәбәпләре күрсәтелергә тиеш

____________________ ____________ __________________________________

вазыйфа имза фамилиясе, исеме һәм ата исеме (булган очракта)

мөһер урыны

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Башкарма комитет җитәкчесенә
____________________________________
ТР муниципаль районы
____________________________________
ТР шәһәр округы

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес: ________________________________________________
____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,
____________________________________________________________________
документны биргән орган атамасы)

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмәдә һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую турында ____________ № ____________ карарда җибәрелгән ________________________________
карар датасы һәм карар номеры
техник хатаны төзәтүегез турында үтенәм.

Техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алуга риза ______________________________
____________________________________________________________________
(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)

«___» _______________ 20___ ел. ______________________ _____________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен һәм аны күрсәткәндә агымдагы контрольлек өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе | Мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында һәм башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган | Мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында һәм башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган |
| Опека һәм попечительлек органы белгече | | |

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе | Мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында һәм башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган | Мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында һәм башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган |

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы | Мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының | Мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы | рәсми сайтында һәм башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган | сайтында һәм башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган |